ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.5, с. Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Узәк ур., 5 нче йорт, Ямбулат
авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.12.2023г. с.Ямбулатово № 109

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә
гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Уставы нигезендә Ямбулат авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенында кабул ителгән 2023 елның 19 ноябрендәге № 1, 2023 елның 19 ноябрендәге №2 карарларны гамәлгә ашыру максатларында Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы урынбасары М. Н. Ахметзянов

Ямбулат авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 4
декабреннән 109 номерлы
карарына

1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә
гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 1.01.2024 елдан 25.03.2024 елга кадәр гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары.

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:
а) уку йортлары студентлары,
б) күп балалы гаиләләр.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.
Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки кечерәйтелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар түләүләрне физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисаплар башкару хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/. сылтама буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша күчерү юлы белән башкара ала.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 4 декабреннән 109 номерлы карарына

2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № ______________

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и.

______________________________________________________________

Адрес: ______________________________________________________

______________________________________________________ нигезендә сезгә ______ кадәр чараларны гамәлгә ашыру өчен _____ күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча:

_______________________________________________________бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

Алучының банкы БИК _______________________________________

Сч. № _____________________________________________

Алучы __ Сч. № ______________________________________

ИНН _________________________________________

КПП _______________________________________

КБК _____________________ОКАТО ____________________

Түләү билгеләү

_________________________________________________________________

Җитәкче ____________________________________________

М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № ________________

үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне бюджетка түләү турында

_________________

(муниципаль берәмлек исеме)

________________ сум күләмендә.

Түләүченең Ф.И.А.и. ___________________________

Адрес: _____________________________________________

Алдым "__" __________________ 20____ ел ________________

(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Әгәр хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырыла икән, киселә торган өлеше тутырыла һәм Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.